**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

07.04.2016　　　　　　　　　　№ 98

«Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында «Комыргуҗа-Яңа Җөлби» автомобиль юлы төзелеше объекты өчен территорияне планлаштыру проекты һәм ызанлау проекты буенча документацияне әзерләү турында

Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү максатларында һәм «ИК Спектр» ОСЮ белдерүенә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында «Комыргуҗа-Яңа Җөлби» автомобиль юлы төзелеше» объекты өчен территорияне ызанлау проектын планлаштыру һәм проектын эшләү турында «ИК Спектр» дигән гариза белән бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45, 46 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2014 елның 16 октябрендәге 31-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьялары, Әтнә муниципаль районы Уставы нигезендә.

карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә һәм Комыргуҗа авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан территорияне планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча документлар әзерләүгә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында «Комыргуҗа-Яңа Җөлби» автомобиль юлын төзү» проектын әзерләүгә керешергә.
2. Әтнә район башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә территорияне планлаштыру документларын әзерләү һәм карап тоту тәртибе, сроклары турында физик һәм юридик затларның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм карауны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatar.ru.)бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

ТР Әтнә район башкарма комитеты җитәкчесе　　　　　　Ф.М. Нуриев